| | | |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**БОЕРЫГЫ** |
| 17.04.2020 | | № 146 |

**Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

«Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2013 елның 29 мартындагы 161 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 31 гыйнварындагы 103 номерлы, 2014 елның 31 октябрендәге 632 номерлы һәм 2015 елның 14 ноябрендәге 671 номерлы, 2017 елның 17 апрелендәге 235 номерлы, 2017 елның 21 августындагы 511 номерлы һәм 2018 елның 13 апрелендәге 154 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эш төркеме составыннан Р.И. Вәлиевны, Р.М. Гарифуллинны, Р.В. Гыйльмановны, В.Н. Демидовны, А.М. Сибагатуллинны, Д.И. Фәттаховны, М.Р. Хисамиевны, А.Р. Шәвәлиеваны чыгарырга;

эш төркеме составына кертергә:

Әюпова Ирада Хафизҗан кызын – Татарстан Республикасы мәдәният министрын;

Гаффаров Рөстәм Гыйльфан улын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарын (килешү буенча);

Дирзизов Альберт Рифкать улын – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручыны;

Зарипов Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисен (килешү буенча);

Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгын;

Соколов Алексей Владимировични – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгын (килешү буенча);

Сөләйманов Тимур Җәүдәт улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасарын;

эш төркеме әгъзаларының вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.Ю. Әминовның – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

А.Г. Барышевның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе башкарма секретаре (килешү буенча)»;

Р.З. Закировның – «Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

В.Е. Козловның – «Педагогика, психология һәм социаль мәсьәләләр институты директоры (килешү буенча)»;

Р.Р. Хәйретдиновның – «Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры (килешү буенча)».

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ